ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2020 Казан ш. № 519-97/тэ-2020

«Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-99/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2021 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2021-2023 елларга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2021-2023 елларга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2023 елларга «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен тарифлар билгеләү хакында» 19.12.2018 № 5-99/тэ карарының 1 нче кушымтасына (Татарстан Республикасы Тарифлар

буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 № 5-111/тэ карары керткән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2018 № 5-99/тэ
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 519-97/тэ-2020
карары редакциясендә)

«Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым белән сайлап алынган пар | | | | Әче һәм редукцияләштерелгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5тән 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0дән 13,0 кг/см$^2$ кадәр | югары 13,0 кг/см$^2$ | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 550,65 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 757,14 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 719,28 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 743,52 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 743,52 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 788,48 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 787,58 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 818,00 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 818,00 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 851,05 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге